**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2025 елның «9» декабреннән № 4-21

2026 елга һәм 2027-2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш фаразы турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Л. К. Исхакова Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының 2026 елга һәм 2027-2028 еллар план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турындагы мәгълүматын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Л. К. Исхакова Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының 2026 елга һәм 2027-2028 еллар план чорына социаль үсеш фаразы турындагы мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының 2026 елга һәм 2027-2028 еллар план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразын хупларга.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәге юнәлешләр буенча эшне дәвам итүне тәкъдим итәргә:

– район территориясендә инвестиция эшчәнлеген активлаштыру;

– эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм итү, сату базарларын киңәйтү өчен онлайн-сәүдә мөмкинлекләрен нәтиҗәле куллану буенча укыту семинарлары һәм консультацияләр үткәрүне кертеп;

– кече һәм урта бизнесның сыйфатлы үсешен стимуллаштыру һәм хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру;

– милли проектларны һәм муниципаль программаларны нәтиҗәлерәк гамәлгә ашыру;

– халыкның керемнәрен арттыру һәм яшәү сыйфатын яхшырту өчен уңай шартлар тудыру;

– керемнәрне легальләштерү һәм ачыкланган хокук бозуларны бетерү чараларын үткәрү ведомствоара комиссиясе эшчәнлеге кысаларында максатчан күрсәткечләрне үтәүне тәэмин итү;

– кече хуҗалыкларга ярдәм итү һәм аларны алга таба үстерүгә ярдәм күрсәтү.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына, барлык төр милек формасындагы предприятие һәм оешма җитәкчеләренә 2026 елга һәм 2027-2028 еллар план чорына социаль-икътисадый үсешнең төп күрсәткечләрен тормышка ашыруга юнәлдерелгән кирәкле чаралар күрергә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы Е.А. Тарнавский